ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/19

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2009 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ санлы Федераль законга, 2007 елның 02 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ санлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге 27/15 карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 12 пунктта:

- 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәһәрне төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне тикшереп тору һәм, Татарстан Республикасының административ хокук бозулар кодексына нигезләнеп, административ хокук бозуларны ачыклау;»

- 2 пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге уникенче һәм унөченче абзац белән тулыландырырга:

«-муниципаль җир контроле органы боерыгын вакытында үтәүне;

- закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итүне.»;

- 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә әйләнә-тирә мохитне саклау буенча чаралар оештыру »;

- 8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) яшел утыртмаларның һәм тышкы төзекләндерүнең башка объектлары сакланышын тәэмин итүне контрольдә тоту, территорияләрне яшел утыртмалар булу-булмауга тикшерү, яшел үсентеләрне казып алган яки казып алуны күздә тоткан очракта китерелгән зыянга исәп-хисап ясау»

- 12 пунктчаны гамәлдән чыккан дип танырга.

2) 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 бүлек. Мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу һәм булдырмау

30. Мәнфәгатьләр каршылыгы – ул АТИ Идарәсе хезмәткәренең шәхси кызыксынуы нәтиҗәсендә вазыйфаи бурычларын тиешенчә башкаруга йогынты ясарга мөмкин булган хәл, андый хәл булганда, АТИ Идарәсе хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм ул эшләгән АТИ Идарәсенең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында Идарәнең милкенә һәм (яйсә) абруена зыян салучы каршылыклыр туа яйсә туарга мөмкин.

31. АТИ Идарәсе хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясаучы яки йогынты ясарга мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык – ул АТИ Идарәсе хезмәткәре тарафыннан, хезмәт вазыйфаларын башкаруга бәйле рәвештә, үзе яки өченче затлар өчен акча, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яки милек характерындагы хезмәтләр рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге.

32. АТИ Идарәсе башлыгы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты Җитәкчесенә вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык хакында хәбәр итәргә тиеш.

33. АТИ Идарәсе хезмәткәре АТИ Идарәсе башлыгына вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык хакында хәбәр итәргә тиеш. АТИ Идарәсе башлыгына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәдә бирелүче мәгълүматлар исемлеге, мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрләрне теркәү тәртибе АТИ Идарәсе башлыгы тарафыннан билгеләнә.»;

3) түбәндәге эчтәлектәге 7 бүлекне өстәргә:

«7 бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре.

34. Юридик зат буларак АТИ Идарәсен үзгәртү һәм бетерү Гамәлгә куючы карары буенча һәм Россия Федерациясе законнарында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

35. АТИ Идарәсен үзгәрткәндә аның барлык документлары хокукый дәвамчысына тапшырыла. Документларны тапшыру гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

36. АТИ Идарәсе суд карары буенча федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә бетерелергә мөмкин.

37. АТИ Идарәсе бетерелгән очракта, кредиторларның таләпләрен кәнәгатьләндергәннән соң калган акча һәм милек Милекчегә тапшырыла.

38. Әлеге Нигезнамәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Гамәлгә куючы карары белән кертелә һәм законда билгеләнгән тәртиптә теркәлергә тиеш.

39. Әлеге Нигезнамә белән җайга салынмаган барлык мәсьәләләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар белән җайга салына.».

2. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Насыйбуллин Айрат Ахмай улына Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча инспекциясендә «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезнамәгә кертелүче үзгәрешләрне дәүләти теркәү буенча вәкаләтләр бирергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшерүне Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме | ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ | Н.Г. Мәһдиев